**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**«15» декабрь 2025 ел** **№ 16**

**2026 елга "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы" муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 50-51, 85 статьялары, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2026 елга "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы" муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) 1нче кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетына 2026 елга «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыруны тәэмин итүне йөкләргә.
3. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Советының сәнәгать, транспорт, төзелеш, торак - коммуналь хуҗалык, эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы Рәисе Д.А. Ишкинеев